КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 май г.Казань № 550

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче; 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1280 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1204 нче, 2020 ел, 15 июнь, 491 нче, 2020 ел, 30 октябрь, 975 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1117 нче, 2023 ел, 7 февраль, 115 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктның егерме бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 683 нче; 2019 ел, 9 август, 669 нчы, 2020 ел, 13 июль, 586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы

яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктның 4 пунктчасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оештыручы тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык һәм шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;»;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан Ә.Н.Әдиятованы, Р.Р.Шакированы чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән эшләү бүлегенең баш белгече, конкурс комиссиясе секретаре Гыйззәтов Ралиф Рафис улын кертергә;

М.Р.Хисамиев вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясенә, 2 бүлекнең унҗиденче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен раслау турында» 2018 ел, 22 август, 694 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын раслау турында» 2019 ел, 23 апрель, 328 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән

субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 17 май, 340 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә, 7 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«оешма чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 414 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 04 сентябрь, 809 нчы, 2022 ел, 22 август, 873 нче, 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә, 5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска

тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 683 нче, 2021 ел, 23 сентябрь, 904 нче, 2022 ел, 22 август, 873 нче, 2022 ел, 11 ноябрь, 1198 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган

торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

14 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»  2021 ел, 05 август, 679 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 873 нче, 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибенә, 5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә

кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 сентябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 873 нче, 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татар теленә тәрҗемә ителгән уку-укыту-методик комплектларны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлегенә кертүгә әзерләү чыгымнарын каплау өчен дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча мәгариф программаларын тормышка ашырганда кулланылырга рөхсәт ителә торган уку ярдәмлекләрен бастырып чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар исемлегенә кертелгән оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә, 5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Адымнар - белемнәргә юл» полилингваль комплекслары өчен укыту-методика комплектларын әзерләүгә һәм бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 24 октябрь, 1133 нче карары белән расланган «Адымнар - белемнәргә юл» полилингваль комплекслары өчен укыту-методика комплектларын әзерләүгә һәм бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «Агентлык» сүзен төшереп калдырырга, «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә,» сүзләрен өстәргә;

5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентган арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

13 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 23 апрель, 328 нче
карары
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 май, 550 нче
карары редакциясендә)

2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы пропаганда концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планы

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы башкаручылар | Башкару срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Матбугат релизлары җибәрү юлы белән басма, электрон һәм челтәр массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат тарату.<br>Интервью һәм матбугат конференцияләре оештыру.<br>Республика башкарма хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан коррупциягә каршы көрәш чаралары турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү | Республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Республика “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 2. | Республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары катнашында, күрсәтелгән органнар эшчәнлегенең ачыклыгына һәм үтә күренмәлелегенә ярдәм итү максатларында интервью һәм матбугат конференцияләре оештыру һәм уздыру | Республика башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), Республика “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | 2030 елга кадәр (елга кимендә 1 тапкыр) |
| 3. | Татарстан Республикасы халкына коррупциячеләрне фаш итү фактлары, вазыйфаи затларны алар биләгән вазыйфалардан | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына (килешү буенча) | ел саен, 2030 елга кадәр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | читләштерү, гаепледәрне җавап-лылыкка тарту турында мәгълү-мат чаралары аша җиткереп тору | | |
| 4. | Эшмәкәрләр белән профилактик эш, шул исәптән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча укыту семинарлары уздыру | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) | квартал саен, 2030 елга кадәр |
| 5. | Россия Федерациясе Торак кодексының нигезләмәләре, торак мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары турында телепрограммаларда (телетапшыруларда) һәм радиопрограммаларда (радиотапшыруларда) яңалыклар сюжетлары әзерләүне, күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмаларны тикшереп тору системасында басмаларда бастырып чыгару юлы белән халыкны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | даими, 2030 елга кадәр |
| 6. | Яшьләр оешмалары эшчәнлеген һәм үткәрелә торган иҗади конкурсларны яктырту максатларында мәгълүмат әзерләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | ярты елга бер, 2030 елга кадәр |

---